# «Татар әдәбияты дәресләрендә тәнкыйди фикерләү технологиясен куллану (мастер-класс)

## Икенче буын федераль белем бирү стандартларына нигезләнгән программалар татар теле һәм әдәбияты укытучылары алдына түбәндәге максат-бурычларны куя:

- 1. әдәби текстны эмоциональ кабул итүне, образлы һәм аналитик фикерләүне, иҗади күзаллауны үстерү;

  2. матур әдәбият әсәрләрен мөстәкыйль уку ихтыяҗы булдыру;

  3. укыган әдәби әсәрнең эчтәлеген, темасын, проблемасын, идеясен беркадәр билгели, геройларын бәяли алуына ирешү;

  4. татар әдәбияты үрнәкләренә үз мөнәсәбәтеңне булдыру күнекмәсен формалаштыру.

  5. укучының мөстәкыйль, иҗади фикерләвен активлаштыру;

# Тәнкыйди фикерләү нигезендә

- · кызыксыну
- · эзләнү,
- · үз-үзеңә сорау кую (ни өчен?)
- · җавап табу,
- · үз фикереңне булдыру,
- · башкалар фикеренә колак салу,
- · кабул ителгән карарга тәнкыйть күзлегеннән карау ята.

Әлеге технология буенча уздырылган дәресләр 3 этаптан тора:

- 1. Кызыксындыру этабы.
- 2. Төшенү этабы.
- 3. Рефлексия этабы.

# “Алты эшләпә” алымы

инглиз язучысы,психолог,тәнкыйди фикерләүөлкәсендә белгеч
Эдвард де Бон тарафыннан эшкәртелгән



# “Алты эшләпә” алымы

- **Ак эшләпә.** Укучы бары тик фактлар белән генә эшләргә тиеш.
- **2.Сары эшләпә.**Укучылар әдәби геройның яки вакыйганың бары тик уңай якларын гына санап чыга. Ни өчен шулай уйлаулары турында да әйтергә онытмыйлар.
- **3. Кара эшләпә.** Бу эшләпәне алган төркем киресен, ягъни вакыйгаларның яки геройларның тискәре яклары турында гына сөйли. Килеп чыккан проблемаларга бәя бирә.
- **4. Кызыл эшләпә.** Бу эшләпә төркеменә хисләр турында сөйләү кирәк. Алардан эмоциональ фикерләү таләп ителә.
- **5. Яшел эшләпә.** Бу эшләпәне алган төркем башкалардан иҗади булуы белән аерылып торырга тиеш.
- **6. Зәңгәр эшләпә**. Бу эшләпә фәлсәфи фикер йөртү турында. Ул дәрескә йомгак ясарга ярдәм итә. Гомуми нәтиҗәләр чыгарыла.

# Ф.Әмирханның "Нәҗип" хикәясендә Нәҗип образы

## Ак эшләпә (фактлар)

Хикәя Нәҗип исемле малайның һөнәргә өйрәнү юлындагы каршылыклары,кайгы –шатлыклары турында,. Бу әсәрдә без кешеләрнең тагын бер күркәм сыйфаты – матурлыкны күрә белү белән очрашабыз. Нәҗипнең дә үзен башкалардан,бигрәк тә Мәрфуга апасыннан, яраттырасы,абыйсы кебек һөнәрле буласы килә. Моның өчен ул койма башына да,өй кыегына да менеп баса,балчыктан төрле сурәтләр дә ясый. Шулай итеп ,һөнәрле булу өчен,нинди киртәләрне генә узмый. Малайның кичерешләре аның начар эшләре белән дә, яхшы эшләре белән дә бәйләнгән. Нәкъ менә кичерешләре Нәҗипне үзгәртә, тәртипле итә. Шуннан соң аның эшләре уңга китә дә инде. Хикәянең ахырына таба Нәҗип мактанмый башлый. Ул үзенең эш-гамәлләрен үзгәртә, үзен-үзе төзәтә. Кыланмый. Теләсә нинди тәртипсезлекләр эшләми. Хисләрен тыя белә башлый. Матур итеп рәсем ясый, димәк, Нәҗип тә һөнәргә ия була. Башкаларга файдалы икәнлегеңне сизү өчен, һөнәр кирәк икән. Нәҗип, үзе белән көрәшеп, дөрес юлга баса

## Сары эшләпә (уңай яклары)

- - акыллы
- - тырыш
- -һөнәрле
- - тәрбияле
- -уйламый эшләгән эшенә үкенә
- - сәләтле
- -максатчан
- - матурлыкны күрә белә

# Кара эшләпә (тәнкыйтьле)

- -мактанчык
- -кылана
- -тәртипсез
- -көнләшүчән
- -һөнәрсез
- -үчле

# Кызыл эшләпә(хисләр)

-ярату

-ачу

-үпкәләү

-мактану

-кайгыру

-соклану

-үкенү

-шатлану

-горурлану

# Яшел эшләпә (башка геройлар белән чагыштыру,иҗат)

- - Егет кешегә җитмеш төрле һөнәр дә аз.
- Оста кулда һөнәр бар.
- Һөнәр утта янмый, суда батмый торган хәзинә.
- Һөнәрле үлмәс, һөнәрсез көн күрмәс.
- Һөнәр ашарга сорамый, үзе ашата.
- Җ.Тәрҗеманов. “Тукран малае Шуктуган”

# Зәңгәр эшләпә (нәтиҗә ясау)

- Шулай булгач, Һөнәрсез кеше атсыз тарантас куган сыман, никадәр кызу чапкан сыман тоелса да, бер урында тора. Файдасыз эш килеп чыга. Һөнәрле кешенең акыл белән эш итүе көймәне алга этәргән җилкән кебек ул. Ул һәрвакыт алга барачак. Акыллы, тыйнак, һөнәрле булу – кешене бизи торган сыйфатлар.



- Бала чакта алынган тәрбияне соңыннан бөтен дөнья халкы үзгәртә алмас.
  - Р. Фәхреддин